РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Брюшлинского сельского
поселения Менделеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлеге Советы

Р Е Ш Е Н И Е
30.05.2025 ел

К А Р А Р
№ 148

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» Бөрешле авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладына «13990» күләмен «15389» сумга алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 14 февралендәге 77 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Карарның 1 нче кушымтасында «19173» санын «21091» санына алмаштырырга, "12,86" санын "15,48" санына алмаштырырга;

2.2. 6 нчы кушымтада «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.;

2.3. Карарның 16 нчы кушымтасында 1 пунктның 3 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Бөрешле авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Бөрешле авыл җирлеге Советы рәисе Л.А. Смирнова